**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

________________ № ________

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыкка каршы яклангалыгын тәэмин итүгә, аларны хосусый сак оешмаларыннан сатып алуны гамәлгә ашырганда хезмәт күрсәтүләр хакының нормативларын раслау һәм 12 сәгатьлек эш режимы белән сак постлары санын билгеләү турында

2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы «Террорчылыкка каршы көрәш турында» Федераль законының 51 статьясы 2 өлешенең 7 пунктына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 24 ноябрендәге 1114 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмалары объектларының (территорияләренең) терроризмга каршы яклануын тәэмин итү белән бәйле хезмәтләр бәяләренең нормативларын раслау, аларны шәхси сак оешмаларыннан сатып алу вакытында, һәм 12 сәгатьлек эш режимлы сак постлары санын билгеләү» (29.12.2021 № 1307, 05.07.2024 № 523 үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 23.11.2021 № 1112 карары белән (07.05.2022 № 423, 28.11.2023 № 1524 үзгәрешләр белән) карары нигезендә,Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының беренче, икенче, өченче, дүртенче куркынычлык категориясендәге муниципаль белем бирү оешмалары объектлары (территорияләре) өчен террорчылыкка каршы яклауны тәэмин итү белән бәйле хезмәт күрсәтү бәяләрен бер саклау постына сәгатенә 235,57 сум күләмендә расларга.

2. Сак хезмәтләре бәяләренең нормативын исәпләү:

| | | |
|---|---|---|
| БЗП-сәгатенә төп хезмәт хакы=МРОТ/СН | 27093/164,3 | 164,90 |
| Двп-ял һәм бәйрәм көннәрендә эшләгән өчен өстәмә түләү (РФ Хезмәт кодексының 153 статьясы) | 27093/30,2(айдагы уртача эш көне)=897,11<br>897,11*100/27093 | 3,31 |
| РО-ялга чыгу резервы | (164,90+3,31)/12 | 14,01 |
| СВ-иминият кертемнәре | (164,90+3,31+14,01)*30,2% | 55,03 |
| Айга турыдан-туры түләүләрнең гомуми суммасы 12 сәг.пост | (164,9+3,31+14,01+55,03)*362,40 | 85979,40 |
| 1 сәгатьлек эш бәясе | 85979,40/365 | 235,57 |

3. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының беренче, икенче, өченче, дүртенче куркынычлык категориясендәге бер муниципаль белем бирү оешмасында 12 сәгатьлек эш режимы белән 1 саклау посты санын билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының өченче, дүртенче куркынычлык категориясендәге муниципаль белем бирү оешмалары объектлары (территорияләре) өчен террорчылыкка каршы яклауны тәэмин итү белән бәйле хезмәтләр күрсәтү бәяләренең нормативына туры китереп гомуми белем бирү учреждениеләрен финанслауны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә дип билгеләргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Ш.Бариев